





# КӨМЕШ КЫҢГЫРАУ

**№4** ДЕКАБРЬ, 2014 нче ел

Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа төп гомуми белем бирү мәктәбе

## Уку елының II чиреге тәмамланды

**Мәктәптәге (Кече Кибәхуҗа төп һәм Олы Кибәхуҗа башлангыч мәктәпләре) 44 укучының 23е (53%) II чирекне “4” һәм “5” билгеләренә тәмамлады.**

**II сыйныф укучысы Мөлекова Динә һәм III сыйныфтан Вәлиева Резедә гел “5” билгеләренә генә тәмамладылар. “4” һәм “5” билгеләренә түбәндәге укучылар өлгерә: II сыйныфтан Закиров Илнур,Нәбиуллин Рөстәм, Рахматуллина Диана.**

**III сыйныфтан Ганина Юлия, Мөхәмәдиева Сиренә, Миннебаев Илназ,Саидов Бахтовар.**

**IV сыйныфтан Гараев Гадел, Шагиева Диләрә.**

**V сыйныфтан Әхмәтҗанова Алия, Шәяхмәтова Сөмбел, Шагиева Фәридә.**

**VI сыйныфтан Әскарова Әдилә, Рахматуллина Энже, Даутова Гөлшат.**

**VII сыйныфтан Саидова Муниса, Саидов Абдулвахоб, Закиров Фәннүр, Серапионов Арслан.**

**VIII сыйныфтан**

**Гыйлметдинова Ләйлә, Ибраһимов Рүзәл**

**IX сыйныфтан**

**Даутова Дилбәр,Сафиуллина Илүзә**

**УҢЫШЛАРЫГЫЗ БЕЛӘН КОТЛЫЙБЫЗ!**



Тагын бер ел артта калды

Борчуы, шатлыклары.

Ак бәхетләр, уңыш теләп

Ява яңа ел кары!

Яңа ел белән сезне!

Яңа бәхетләр белән!

Яңа елда уңышлар,

Телибез сезгә дуслар!

## Башлангыч сыйныфлар атналыгы



**1 нче декабрьдән алып 6 нчы декабрьга кадәр мәктәбебездә (Кече Кибәхужа төп һәм Олы Кибәхужа башлангыч мәктәпләре) башлангыч сыйныфларның татар теле атналыгы булып үтте. Атналыкның максаты һәм бурычлары:татар теле фәне белән кызыксынуны арттыру;игътибарлылыкны,ижади фикерләүне үстерү;үзбелемеңне бәяли һәм үзеңнең эшчәнлегеңне дөрес планлаштыра белү күнекмәләрен формалаштыру; үзара ярдәмләшү, бердәмлек һәм жаваплылык сыйфатлары тәрбияләү булды.Атна дәвамында"Иң матур язу" конкурсы, “Сөйдергән дә тел”дигән журнал, “Татар теле-туган телем” исемле әдәби – музыкаль иртә, “Тапкырлар бәйгесе”,”Башваткыч” тапшыруы , “Тел бәйгесе”игълан ителде.**





## 3 нче декабрь – Билгесез солдат көне

3 декабрь- Билгесез Солдат Көне. Мәктәптә шушы датага багышланган чара үткәрелде.Бөек Ватан һәм Беренче бөтендөнья сугышларында бик күп солдатлар-ватандашларыбыз вафат булган, кайберләренең исемнәре эзтабарлар армый-талмый эзләсәләр дә, бүгенге көндә дә билгесез.Бу бәйрәм- сугышта хәбәрсез югалганнарны искә алу бәйрәме.



9 декабрь-Ватан Геройлары көне.

Бу - Россиядә билгеләнеп үтүче мөһим бәйрәм.Әлеге истәлекле дата РФ Дәүләт думасы карары нигезендә 2007 елда билгеләнгән. Ватан Геройлары көнен билгеләү тарихы 1917 елга барып тоташа. Бу көнне Георгий кавалерлары батырлыкларын хөрмәтләгәннәр. РФ Дәүләт Думасы кабул иткән карарда РФ Геройларын гына түгел, шулай ук, Советлар Союзы геройларын да, Изге Георгий һәм Дан орденнары кавалерларын да хөрмәтләүне тәкъдим итә.

Бәйрәм бөтен Россиядә зурлап билгеләп үтелә. Бу традиция безнең мәктәптә дә саклана. Сыйныфларда батырлык дәресләре, презентация, фильмнар күрсәтү оештырылды.




## Халыкара коррупцияга каршы көрәш көне.

9 декабрь - Халыкара коррупциягә каршы көрәш көне. Шул уңайдан мәктәбебездә күптөрле чаралар булып үтте. Һәр сыйныф җитәкчесе, укучыларның яшь үзенчәлекләреннән чыгып, сыйныфларда рольле уеннар үткәрде, презентацияләр күрсәтте. Югарырак сыйныф укучылары коррупциягә каршы көрәштә кулланыла торган законнар, карарлар белән таныштылар.




Бөтенроссия "Код сәгате" 11 нче декабрь көнне **укучыларда информатика фәне, программалаштыру белән кызыксыну уяту максатыннан, мәктәбебездә "Код сәгате" исемле дәрес- вакыйга булып үтте.Код сәгатендә 8-9 сыйныф укучылары "Блокли" программалаштыру телендә "Лабиринт"онлайн тренажер үтеп, сертификатлар алдылар.**

## Хәзерге заман белем бирү тирәлеген булдыру юлында



8 нче декабрьдән алып 12 нче декабрьгә кадәр укыту- тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Ф.Г.Әскарова районыбызның бертөркем директор урынбасарлары белән Казан шәһәренең 146 номерлы мәктәбендә "Белем бирү белән идарә итүнең яңа модельләрен проектлау" темасы буенча стажировка үтте. Стажировка үтүчеләр 146нчы мәктәпнең идарә итү системасындагы алдынгы тәҗрибәсен өйрәнде, тренингларда, түгәрәк өстәл артларында тәҗрибә уртаклашты, дәресләрдә катнашты.

## Макулатура җыю



Декабрь аенда мәктәбебездә макулатура җыю өмәсе оештырылды. Укучылар тырышлыгы белән барысы 99,1 кг. макулатура җыеп тапшырылды. Аеруча 4,6,3 нче сыйныф укучылары активлык күрсәтте. Укучылар җыелган һәр килограммның агач гомерен саклап калганын,кәгазь эшләүдә җиңеллек тудырганын аңлап эш итәләр. Макулатура җыю эше дәвам итә.

## *Кешенең биш асылы*



17 нче декабрь көнне китапханәче һәм физика, химия укытучысы Х.Н.Нигъмәтҗанова "Бәһасе юк бәһаләр, ягъни кешенең биш асылы" дигән темага ачык тәрбияви чара үткәрде. Чара бүгенге көннең актуаль проблемасы - укучыларда күркәм сыйфатлар тәрбияләүгә багышланды. Тәрбияви иртәдә презентация файдаланылды, 6 нчы сыйныф укучысы Әскарова Әдилә Ә.Ерикәйнең "Намус" шигырен укыды, 9 нчы сыйныф укучысы Сафиуллина Илүзә "Мәрхәмәтсезләр" исемле хикәянең эчтәлеге белән таныштырды. Чара "Бәхет үз кулында" сүзләре белән тәмамланды.



## *Республикакүләм семинарда*



17 декабрь көнне мәктәбебезнең башлангыч сыйныфлар укытучысы, башлангыч сыйныф укытучылары методик берләшмәсе җитәкчесе Гарипова Г.З. Казан шәһәрендә "Хәзерге заман белем бирү ресурслары-планлаштырылган белем бирү нәтиҗәләре гарантиясе" дип исемләнгән республикакүләм мәгълүмати-методик семинарда катнашты. Семинарда катнашучылар "Академкнига" нәшриятының белем бирү проектлары мисалында шушы нәшрият дәреслекләре белән эшләү үзенчәлекләре турында фикер алыштылар,яңа буын ФГОСка күчкәндә укытучының ролен ачыкладылар. Шушы көннәрдә тема буенча башлангыч сыйныф укытучыларының семинары планлаштырыла.

## Татар әдәбияты олимпиадасы призеры



17 нче декабрь көнне Иске Җөри урта мәктәбендә татар мәктәпләрендә, татар сыйныфларында укучы балалар өчен татар әдәбиятыннан республика олимпиадасының муниципаль туры булып узды. Олимпиаданың муниципаль турында безнең мәктәпнең 9 нчы сыйныф укучысы Даутова Дилбәр катнашты һәм призлы урын яулады. Укучыны олимпиадага беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Закирова Гөлназ Миннехановна әзерләде. Уңышыгыз белән котлыйбыз.



### Президент чыршысы бәйрәмендә

***21 декабрь көнне "Татнефть - арена" да Республикакүләм чыршы бәйрәме булып үтте.Бәйрәмгә республикабыздан иң сәләтле, иң актив балалар килгән иде. Президент Рөстәм Миннеханов кунакларга :" Бүген республика чыршы бәйрәменә безнең өметле киләчәгебез җыелды. Сез иң яхшы, иң сәләтле, иң спорт сөючән балалар". Үз чыгышында ул республикабызның алга таба чәчәк атуында малайлар һәм кызлар барысын да эшләр дигән ышаныч белдерде. Мәктәбебездән чыршы бәйрәмендә 6 сыйныф укучысы Закирова Алинә һәм 7 нче сыйныф укучысы Серапионов Арслан катнашты.***

## *“Әкият”тә - кунакта*



26 нчы декабрь көнне мәктәбебезнең бертөркем укучылары Нигъмәтҗанова Хәдичә Нургалиевна җитәкчелегендә дәрәҗәле авылдашыбыз Закиров Роберт Камил улы чакыруы буенча Казан шәһәренә "Әкият" курчак театрын тамаша кылырга юл алды. Укучылар "Әкият" курчак театрында "Кыш бабай бүләкләре" спектаклен караячак, курчак театры музеенда булачак. Соңыннан "Туган авылым" мәдәни- күңел ачу үзәгендә ял итәчәк. Мәрхәмәтле авылдашыбызга балаларга ясаган зур яңа ел бүләге өчен рәхмәт белдерәбез.



# Ватан геройларын онытмый

Мәктәптә шушы исем астында рәсемнәр, плакатлар, җырлар конкурсы булып үтте. Конкурсны сыйныф җитәкчеләре методик берләшмәсе җитәкчесе Арсланова И.М. үткәрде. Конкурста 2-9 сыйныф укучылары актив катнашты. Ватан геройлары алдында һәркем бурычлы икәнлегенә инандылар.

Без Җиңүнең нинди корбаннар хакына яулап алынуын беркайчан да онытырга тиеш түгелбез. Иделдән алып Дунай ярына һәм Шпрейга кадәр, шәһәрләр, поселоклар һәм авыллар буйлап Татарстан уллары һәм кызларының каберләре тора, һәйкәлләр калка. Без, җиңүчеләрнең оныклары, моңа кадәр сугыш корбаннарының саны турында бихәбәр булдык. Бүгенге көндә 27 миллион тирәсе дигән мәгълүмат бар. Ләкин никадәр генә булмасын, алар турында истәлекне безнең күңелләрдән беркем дә җуя алмас. Хәзергә кадәр хәбәрсез югалганнарның каберләрен эзләү, исемнәрен барлау дәвам итә. Хәтер китабының 27 томы рус һәм татар телләрендә басылып чыкты. Геройлар даны мәңгелек! Беркем дә, бернәрсә дә онытылмас!

Бүген һәркайсыбызның күңеле бер уй, бер теләк белән сугарылган: Туган илебез туфрагын дошман танклары таптамасын, күкләребез гел аяз, ил – көннәребез имин булсын!






# *Туган көннәрегез котлы булсын!*

***Хөрмәтле Рәхмәтуллина Айгөл Әбүзәровна һәм Шәйхетдинова Фидәния Нәкыйповна!***

**Сезне үзегезгә генә хас бәйрәмегез- Туган көнегез белән тәбрик итәбез. Сезгә иң изге, якты, матур теләкләребезне юллыйбыз:көчле рухлы һәм кешелекле, юмарт һәм ярдәмчел, бәхетле һәм сәламәт булыгыз! Уй – теләкләрегез тормышка ашсын, туар таңнарыгыз тыныч, саулыгыгыз нык, гомерегез бәхетле булсын!**

**Кояш мәңге көлсен Сезгә**
**Юлыгызга үссен гөлчәчәк.**
**Бүгенге көн гүзәллегеннән дә**
**Гүзәл булсын Сезнең киләчәк!**

**Укучылардан: IIсыйныф укучысы Рәхмәтуллина Диана, IVсыйныф укучысы Гыймадиев Илүс, VII сыйныф укучылары Сәидов Абдулвахоб, Шәйхетдинов Фирдүсләрнең декабрь аенда туган көннәре.**

## Кадерле укучылар!

Сезне туган көннәрегез белән тәбрик итәбез. Сезгә аяз күк йөзе, корычтай нык сәламәтлек, кояштай озын гомер, чиксез шатлыклар телибез! Мәрхәмәтле, ярдәмчел булыгыз. Һәрвакыт киң күңелле, ачык йөзле, олы йөрәкле булырга тырышыгыз. Әти-әниләрегез белән алдагы көннәрегездә дә сәламәтлек белән гомер итәргә, шатлыкларга, уңышларыгызга сөенеп яшәргә язсын. Әти-әниләрегезгә игелекле балалар булыгыз.

# Хуш киләсең Яңа ел!



27 декабрь көнне мәктәбебездә Яңа елны каршылауга багышланган бәйрәм кичәләре булып үтте. Көндезге бәйрәмдә башлангычлар һәм бишенче сыйныфлар күңел ачты. Кичен 6-9 нчы сыйныф укучылары өчен Балмаскарад үтте. Бәйрәмдә мәктәп директоры Әхмәтҗанова Н.Н. әти-әниләрне укучыларның уңышлары белән таныштырды, котлау сүзләре җиткерде. Бәйрәм бик күңелле үтте.











Газетаны гамәлгә куючы: ТР Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа төп мәктәбе .Адрес:422080, ТР, Теләче районы, Кече Кибәхуҗа авылы, Кече урам, 10 нчы йорт.
E-mail: mkibiakozi40@mail.ru
Редактор: Хәбибуллина Л.И.
Редколлегия әгъзалары: V сыйныф укучылары